СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

____________________ с. Сарманово №_______________

22.05.2023 ел №144

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 2020 елның 14 маендагы 234 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 8 өлеше, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2023 елның 17 мартындагы 10/13-09/1230 номерлы хаты, «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советы карар итте:

1. «Муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 2020 елның 14 маендагы 234 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы

Советы рәисе Ф.М.Хөснуллин